**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Яңа Сәет торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 11 декабре** **№ 10**

Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Яңа Сәет авылы биләмәсендә гражданнар җыенының 2025 елның 30 октябрендәге 3 номерлы карарында хокукый норманы дөрес кулланмау сәбәпле, гражданнар җыенының 2025 елның 11 декаберендә узган җыен нәтиҗәләре белән беркетмәсе төзелде: «Гражданнар җыенының 2025 елның 30 октябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә ризамы Сез», карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә»» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә»» сүзләренә алмаштырырга.

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында **120** катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 70 кеше кертелде, бу **5Ә %** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 70 катнашучысы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен җыенның **0** катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Яңа Сәет авылы биләмәсендә гражданнар җыенының 2025 елның 30 октябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, гражданнар җыены карары преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә»» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә»» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында»: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://muslumovo.tatarstan.ru, гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Сәет авылында, Мирная урамында, 46 нче йорт янында мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Исәнсеф авыл җирлеге башлыгы** **И. А. Салихов**